**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 29 ноябре** **№ 2**

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы территориясендә I нче группа инвалидлар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә улэн чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, триммер очен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү), Чокырлы урамында шлагбаум кую өчен материаллар сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Мостафин торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча түләү; зират территориясендә улэн чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, триммер очен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу; коры агачларны кисү һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

- Мостафино авылында җир асты суларын (чишмәләрне) территориясен төзекләндерү, беседка ясау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү)?;

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов